**11нче билет**

| | |
|---|---|
| **1. Бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән 3-4 җөмлә төзегез, тәрҗемә итегез.**<br>Белән, кебек, шикелле, өчен, хәтле. Кадәр,аркылы, буенча, сәбәпле. | 1. Белән - с, кебек - как, шикелле - как, өчен - для, хәтле - до. Кадәр - до, аркылы - через, буенча - по, сәбәпле - из-за (по причине).<br><br>Малай юл аша йөгереп чыкты. Төнгә кадәр дәрес әзерләде. Синең өчен бу күнегү авыр түгел. |
| **2. Шигырьнең эчтәлеген сөйләгез.**<br>Ә ни өчен?<br>Үпкәләшми яшәп була Алдашмый да яшәп була<br>Төрткәләшми яшәп була Елашмый да яшәп була<br>Була да бит, яшәмибез. Була да бит, яшәмибез.<br>Ә ни өчен? Ә ни өчен?<br>Әрепләшми яшәп була Тату гына яшәп була<br>Әләкләшми яшәп була Матур гына яшәп була<br>Була да бит, яшәмибез. Була да бит, яшәмибез.<br>Ә ни өчен? Ә ни өчен?<br>Ялкаулашмый яшәп була, Синең эшең,<br>Һәм шаулашмый яшәп була. Югыйсә ул<br>Була да бит, яшәмибез. Минем эшем!<br>Ә ни өчен?<br>Р. Миңнуллин | 2. Бу шигырьдә кешеләрнең үзара ничек яшәүләре турында сүз бара. Автор кешеләргә төрткәләшмичә, әрепләшмичә, ялкаулашмыйча, алдашмыйча елашмыйча, тату, матур яшәп була, ди. |
| 3. **Тәрҗемә итегез.**<br>1) Берничә көн томан булу аркасында, самолетлар оча алмады.<br>2) Яктылык җитмәгәнлектән, гөлләр начар үсәләр.<br>3) Табигатьне яратырга кирәк, чөнки ул күңелләрне дәвалый. | 3.<br><br>1) Самолёты не могли летать,из-за того что несколько дней был туман.<br>2) Цветы плохо росли из-за недостатка света.<br>3) Нужно любить природу, так как она лечит души. |

| | |
|---|---|
| **4. Как скажете, если:**<br>- вы часто общаетесь с друзьями в интернете;<br><br>- и среди девочек, и среди мальчиков у вас есть хорошие друзья;<br>- вы любите проводить свободное время с друзьями;<br><br>- ваш друг – отзывчивый человек;<br><br>- в интернете вы нашли старых друзей? | 4. Мин дусларым белән интернет аша аралашам. Малайлар арасында да, кызлар арасында да минем яхшы дусларым бар. Буш вакытны дусларым белән уздырырга яратам. Минем дустым – ярдәмчел кеше. Интернетта күптәнге дусларымны таптым. |
| **5. “Дуслар белән аралашу һәрвакыт күңелле” дигән темага сөйләргә әзерләнегез.** | 5. Дуслар белән аралашу һәрвакыт күңелле<br>Минем дусларым күп. Малайлар арасында да, кызлар арасында да яхшы дусларым бар. Алар минем белән бер сыйныфта укыйлар. Мәктәптә дә, урамда да без бергә.<br>Дуслар белән аралашу һәрвакыт күңелле. Буш вакытны дусларым белән уздырырга яратам. Дусларым белән бергәләшеп китап укырга яратабыз, төрле уеннар уйныйбыз, яхшы укырга тырышабыз. Без һәрвакыт бер-берләребезне аңлыйбыз, кайгы килгәндә, ярдәмгә ашыгабыз, шатлык-сөенечләрне бергә уртаклашабыз. |